КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 4 июль г.Казань № 622

Татарстан Республикасының Балтач муниципаль районы территориясендә «Чепья урманы» табигать объектын төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле дип игълан итү турында

«Махсус сакланыла торган табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, табигый һәм ясалма нарат, чыршы һәм ак чыршы утыртмаларын саклап калу, үсемлекләрне һәм хайваннарны (шул исәптән Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгәннәрне) саклау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә 118,9 гектар гомуми мәйданлы «Чепья урманы» табигать объектын – төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле, ә ул биләгән территорияне төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территориясе дип игълан итү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Чепья урманы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле турындагы нигезләмәне;

«Чепья урманы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле чикләре урнашу урынының график тасвирламасын.

3. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына:

Татарстан Республикасының махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләр кертү турындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

законнар белән билгеләнгән тәртиптә «Чепья урманы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле чикләре турындагы мәгълүматларны «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына бирүне тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 4 июль, 622 нче карары белән расланды

«Чепья урманы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Чепья урманы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле (алга таба – табигать һәйкәле) – табигый һәм табигый булмаган нарат, чыршы һәм ак чыршы утыртмаларын саклап калу, үсемлекләрне һәм хайваннарны, шул исәптән Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгәннәрне саклау максаты белән төзелгән төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территориясе.

Табигать һәйкәле Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан һәм аның гомуми мәйданы 118,9 гектар тәшкил итә.

1.2. Табигать һәйкәле Татарстан Республикасының табигать-тыюлык фонды составына керә.

Табигать һәйкәленең чикләре җирлектә махсус мәгълүмат билгеләре белән билгеләнә.

1.3. Табигать һәйкәле Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Комитет) карамагында.

1.4. Табигать һәйкәленең чикләре һәм махсус саклау режимы үзенчәлекләре территориаль планлаштыру документларын әзерләгәндә, урман хуҗалыгы регламентларын һәм урманнарны үзләштерү проектларын эшләгәндә, урман хуҗалыгы эшчәнлеген башкарганда һәм җирләрне инвентаризацияләгәндә исәпкә алына.

## II. Табигать һәйкәле эшчәнлеген оештырганда Комитетның төп бурычлары

2.1. Табигать һәйкәле эшчәнлеген оештырганда Комитетның төп бурычлары:

биологик төрлелекне саклап калуны тәэмин итү;

хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясавын булдырмау;

төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре системасын үстерү һәм камилләштерү.

## III. Табигать һәйкәле эшчәнлеген оештыру буенча Комитетның функцияләре

3.1. Комитет табигать һәйкәле эшчәнлеген оештыру буенча үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыра:

хайваннар дөньясы объектларын саклау, яңадан үрчетү белән идарә итү, хайваннар дөньясы объектларын файдалануны җайга салу;

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрен оештыру һәм аларның эшләве өлкәсендә идарә итү, Татарстан Республикасы Кызыл китабын алып бару;

махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) (табигать дәвалау ресурсларын, дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны санитария (тау санитариясе) нигезендә саклауны тәэмин итү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) кертеп).

## IV. Табигать һәйкәленең махсус саклау режимы

4.1. Табигать һәйкәле территориясендә табигать комплексларына тискәре (зарарлы) йогынты ясый торган теләсә нинди эшчәнлек тыела, шул исәптән:

бу Нигезләмәнең 4.2 пунктындагы икенче абзацында каралган очраклардан тыш, биналар, төзелмәләр, корылмалар төзү;

бу Нигезләмәнең 4.2 пунктындагы дүртенче абзацында каралган очраклардан тыш, капиталь төзелеш объектларын, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, бакчачылыкны һәм яшелчәчелекне алып бару өчен җир кишәрлекләре бирү;

автотранспорт чараларын һәм авыл хуҗалыгы техникасын юу;

табигать һәйкәле эшчәнлегенә бәйле булмаган гидромелиорация һәм ирригация эшләрен башкару;

учаклар кабызу, корыган яфракларны һәм үләннәрне яндыру;

барлык төрләрдәге калдыкларны урнаштыру, туфракларны, грунтларны, җир өсте һәм җир асты суларын пычрату;

материалларны, грунтларны, карны оеп кую;

туфрак катламын бозу, җир эшләрен башкару (урманнарның янгынга каршы корылышы чараларын башкарудан, фәнни тикшеренүләр үткәрүдән тыш, шулай ук бу Нигезләмәнең 4.2 пунктындагы икенче абзацы нигезендә рөхсәт ителә торган объектлар төзүгә бәйле очраклардан тыш);

яшәү тирәлегеннән алып, хайваннар дөньясы объектларыннан файдалану, шулай ук хайваннар дөньясы объектларына зыян китерү (хайваннар дөньясы объектларын фәнни максатларда, һәвәскәр һәм спорт аучылыгы максатларында файдаланудан, аларның санын җайга салу, шулай ук сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар дөньясы объектларының популяцияләрен торгызу буенча чараларны гамәлгә ашырудан тыш);

хайваннарның ояларын, өннәрен һәм башка яшәү урыннарын бетерү, шулай ук кыргый хайваннарны борчуга китерә торган башка гамәлләр кылу;

агачларны, куакларны кисү һәм (яки) үсемлек капламын бозу (урманнарның янгынга каршы корылышы буенча чаралар, урманнарны саклау, яклау һәм яңадан үстерү чараларын үткәрүдән, шулай ук табигать комплексларын һәм табигать һәйкәле объектларын саклап калу һәм яңадан торгызу максатларында әлеге эшчәнлек гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш);

печән чабу;

файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару, файдалы казылмалар ятмаларын эзләүне һәм бәяләүне үз эченә алган геологик өйрәнү, шулай ук җир асты байлыклары кишәрлекләренең файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен яраклылыгын геологик өйрәнү һәм бәяләү;

киртәләргә, аншлагларга, шлагбаумнарга, стендларга, чик баганаларына, күрсәткечләргә һәм башка мәгълүмат билгеләренә, эшләнгән экологик сукмакларга, төзелмәләргә һәм корылмаларга зыян салу, агачларга язулар һәм билгеләр төшерү;

механик транспорт чаралары (түбәндәгеләрнең механик транспорт чараларыннан, махсус техникасыннан тыш) йөрү һәм аларны вакытлыча куеп тору:

махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органнарның;

табигать һәйкәле чикләрендә вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган башка дәүләт һәм муниципаль органнарның;

линия объектларына хезмәт күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру, аварияләрне, табигый бәла-казаларны һәм гадәттән тыш характердагы башка хәлләрне бетерү чараларын үткәрү өчен файдаланыла торган;

шулай ук түбәндәгеләрнең механик транспорт чараларыннан тыш:

аучылык хуҗалыгы килешүләре нигезендә хайваннар дөньясыннан файдалануны гамәлгә ашыручы юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең;

шартнамәләр нигезендә табигать һәйкәле территориясендә хезмәт күрсәтүче юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең;

табигать һәйкәлендә табигать комплексының экологик тигезлеген боза торган, бу территориянең экологик кыйммәтен киметә яки хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының саклана торган объектларына һәм аларның яшәү тирәлегенә зыян китерә торган башка эшчәнлек төрләре.

4.2. Табигать һәйкәле территориясендә, Комитет белән килештереп, түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

табигать һәйкәлен булдыру максатларына ирешүгә һәм аның төп бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектлар төзү һәм реконструкцияләү; яңа инженерлык һәм техник коммуникацияләр төзү, элек төзелгәннәрне реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау (табигать һәйкәле чикләреннән читтә аларны урнаштыру вариантлары булмаган очракта); элегрәк төзелгән капиталь төзелеш объектларын, шул исәптән линия объектларын реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау;

бу пунктның икенче абзацы нигезендә рөхсәт ителә торган объектларны төзү өчен җир кишәрлекләре бирү;

төбәк геологиясен өйрәнү;

җир кишәрлекләрен экологик тернәкләндерү һәм рекультивацияләү;

үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларын, шул исәптән Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән төрләрне, шулай ук аларның яшәү тирәлеге мохитен саклау чараларын гамәлгә ашыру;

үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларының, шул исәптән Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән төрләрнең яшәү тирәлеге шартларын яхшыртуга ярдәм итә торган профилактика чараларын үткәрү;

җирле флорага һәм фаунага чит булган үсемлекләрне һәм хайваннарны интродукцияләү;

урманнарны саклау, яклау һәм яңадан үстерү чараларын үткәрү, урманнарны яклау буенча профилактик чаралар, санитария-савыктыру чаралары, шул исәптән һәлак булган һәм зыян күргән урман утыртмаларын кисү (1 апрельдән 31 июльгә кадәр ояда утыру һәм балалар чыгару чорында агачлар кисүдән тыш);

экологик туризмны гамәлгә ашыру;

биологик төрлелекне, табигать объектларын һәм комплексларын өйрәнүгә һәм яңадан торгызуга, мәдәни мирас объектларын өйрәнүгә һәм саклап калуга юнәлдерелгән фәнни тикшеренүләр үткәрү.

4.3. Табигать һәйкәле территориясендә хуҗалык эшчәнлеге бу Нигезләмәгә һәм җитештерү процессларын гамәлгә ашырганда, шулай ук «Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә расланган транспорт магистральләрен, торба үткәргечләрне, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен эксплуатацияләгәндә хайваннар дөньясы объектларының һәлак булуын булдырмау таләпләренә таянып гамәлгә ашырыла.

## V. Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре

5.1. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы боерыгы нигезендә табигать һәйкәле чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдаланының түбәндәге төп төрләре, әгәр алар бу Нигезләмәнең IV бүлегендәге таләпләренә каршы килмәсә, рөхсәт ителә:

фәнни тикшеренүләр үткәрү (Комитет белән килештереп) (3.9.2*);

табигатьне танып белү туризмы (Комитет белән килештереп) (5.2*);

аучылык һәм балыкчылык (Комитет белән килештереп) (5.3*);

элемтә (Комитет белән килештереп) (6,8*);

торба үткәргеч транспорт (Комитет белән килештереп) (7.5*);

табигать территорияләрен саклау (9.1*);

тарихый-мәдәни эшчәнлек (Комитет белән килештереп) (9.3*);

агач әзерләү (Комитет белән килештереп) (10.1*);

урман плантацияләре (Комитет белән килештереп) (10.2*).

---

*Код билгеләнеше Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы буенча.

## VI. Табигать һәйкәле территориясендә рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик максималь параметрлары

6.1. Табигать һәйкәле территориясендә рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик максималь параметрлары:

биналар, төзелмәләр, корылмаларның иң чик биеклеге – 18 метр;

җир кишәрлеге чикләрендә төзелеш проценты – иң күбе 50 процент.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 4 июль, 622 нче
карары белән расланды

«Чепья урманы» төбәк әһәмиятендәге
табигать һәйкәле чикләре урнашу урынының график тасвирламасы

1 бүлек

| Объект турында мәгълүматлар | | |
|---|---|---|
| Т/с | Объектның тасвирнамәләре | Тасвирнамәләрнең тасвирламасы |
| 1 | Объектның урнашу урыны | Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы |
| 2 | Объектның мәйданы +/- мәйданны билгеләү төгәлсезлеге зурлыгы (P +/- Дельта P) | 1 188 869 кв.метр +/- 90 768 кв.метр |
| 3 | Объектның башка тасвирнамәләре | - |

2 бүлек

| Объект чикләренең урнашу урыны турында мәгълүматлар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Координатлар системасы: Халыкара координатлар системасы – 16 | | | | | |
| 2. Объект чикләренең характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | |
| Чикләрнең характерлы нокталары билгесе | Координатлар, метр | | Характерлы ноктаның координатларын билгеләү ысулы | Характерлы нокта урынының уртача квадрат төгәлсезлеге (Mt), метр | Җирлектә нокта билгесенең тасвирламасы (булганда) |
| | X | Y | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | 562215.86 | 1378203.92 | Картометрик | 12.50 | - |
| 2 | 562224.27 | 1378251.31 | Картометрик | 12.50 | - |
| 3 | 562196.83 | 1378319.17 | Картометрик | 12.50 | - |
| 4 | 562183.57 | 1378387.51 | Картометрик | 12.50 | - |
| 5 | 562140.24 | 1378406.31 | Аналитик | 3.00 | - |
| 6 | 562115.99 | 1378390.31 | Аналитик | 7.50 | - |
| 7 | 562098.99 | 1378375.81 | Аналитик | 7.50 | - |
| 8 | 562091.99 | 1378366.31 | Аналитик | 7.50 | - |
| 9 | 562074.74 | 1378356.06 | Аналитик | 7.50 | - |
| 10 | 562062.74 | 1378343.31 | Аналитик | 7.50 | - |
| 11 | 562044.24 | 1378320.56 | Аналитик | 7.50 | - |
| 12 | 562021.99 | 1378294.56 | Аналитик | 7.50 | - |
| 13 | 562009.49 | 1378286.31 | Аналитик | 7.50 | - |
| 14 | 562002.49 | 1378283.81 | Аналитик | 7.50 | - |
| 15 | 561987.24 | 1378283.81 | Аналитик | 7.50 | - |
| 16 | 561955.99 | 1378283.06 | Аналитик | 7.50 | - |
| 17 | 561929.49 | 1378293.81 | Аналитик | 7.50 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 18 | 561926.24 | 1378297.06 | Аналитик | 3.00 | - |
| 19 | 561898.24 | 1378311.06 | Аналитик | 3.00 | - |
| 20 | 561877.22 | 1378326.01 | Картометрик | 12.50 | - |
| 21 | 561815.90 | 1378288.51 | Картометрик | 12.50 | - |
| 22 | 561864.39 | 1378183.47 | Картометрик | 12.50 | - |
| 23 | 561864.52 | 1378131.43 | Картометрик | 12.50 | - |
| 24 | 561781.48 | 1378079.25 | Картометрик | 12.50 | - |
| 25 | 561691.60 | 1378069.69 | Картометрик | 12.50 | - |
| 26 | 561633.42 | 1378095.92 | Картометрик | 12.50 | - |
| 27 | 561594.90 | 1378068.05 | Картометрик | 12.50 | - |
| 28 | 561461.86 | 1378042.37 | Картометрик | 12.50 | - |
| 29 | 561290.70 | 1378062.55 | Аналитик | 3.00 | - |
| 30 | 561275.95 | 1378057.55 | Аналитик | 3.00 | - |
| 31 | 561269.70 | 1378051.05 | Аналитик | 3.00 | - |
| 32 | 561251.24 | 1378018.88 | Картометрик | 12.50 | - |
| 33 | 561206.70 | 1378006.55 | Аналитик | 3.00 | - |
| 34 | 561176.95 | 1377994.55 | Аналитик | 3.00 | - |
| 35 | 561163.70 | 1377994.05 | Аналитик | 3.00 | - |
| 36 | 561145.95 | 1378002.30 | Аналитик | 3.00 | - |
| 37 | 561117.20 | 1378025.80 | Аналитик | 3.00 | - |
| 38 | 561071.45 | 1378073.30 | Аналитик | 3.00 | - |
| 39 | 561035.45 | 1378116.55 | Аналитик | 3.00 | - |
| 40 | 561018.08 | 1378135.90 | Картометрик | 12.50 | - |
| 41 | 560969.20 | 1378219.30 | Аналитик | 3.00 | - |
| 42 | 560934.08 | 1378277.95 | Картометрик | 12.50 | - |
| 43 | 560841.47 | 1378208.56 | Картометрик | 12.50 | - |
| 44 | 560814.16 | 1378180.70 | Картометрик | 12.50 | - |
| 45 | 560766.62 | 1378155.84 | Картометрик | 12.50 | - |
| 46 | 560781.45 | 1378103.80 | Аналитик | 7.50 | - |
| 47 | 560804.20 | 1378079.05 | Аналитик | 7.50 | - |
| 48 | 560811.70 | 1378067.05 | Аналитик | 7.50 | - |
| 49 | 560821.45 | 1378042.30 | Аналитик | 7.50 | - |
| 50 | 560814.95 | 1378019.30 | Аналитик | 7.50 | - |
| 51 | 560795.20 | 1378005.30 | Аналитик | 7.50 | - |
| 52 | 560784.38 | 1377997.26 | Картометрик | 12.50 | - |
| 53 | 560768.26 | 1377931.01 | Картометрик | 12.50 | - |
| 54 | 560724.55 | 1377921.73 | Картометрик | 12.50 | - |
| 55 | 560687.13 | 1377925.28 | Картометрик | 12.50 | - |
| 56 | 560636.64 | 1378090.39 | Картометрик | 12.50 | - |
| 57 | 560460.68 | 1378035.69 | Картометрик | 12.50 | - |
| 58 | 560114.30 | 1377918.14 | Картометрик | 12.50 | - |
| 59 | 559800.91 | 1377919.31 | Картометрик | 12.50 | - |
| 60 | 559642.00 | 1377885.11 | Картометрик | 12.50 | - |
| 61 | 559279.02 | 1377785.37 | Картометрик | 12.50 | - |
| 62 | 559318.87 | 1377589.57 | Картометрик | 12.50 | - |
| 63 | 559366.32 | 1377529.44 | Картометрик | 12.50 | - |
| 64 | 559432.57 | 1377519.17 | Картометрик | 12.50 | - |
| 65 | 559560.32 | 1377444.26 | Картометрик | 12.50 | - |
| 66 | 559558.62 | 1377394.33 | Картометрик | 12.50 | - |
| 67 | 559599.10 | 1377370.81 | Картометрик | 12.50 | - |
| 68 | 559843.35 | 1377287.19 | Картометрик | 12.50 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 69 | 560002.86 | 1377361.20 | Картометрик | 12.50 | - |
| 70 | 560067.32 | 1377331.78 | Картометрик | 12.50 | - |
| 71 | 560120.59 | 1377282.13 | Картометрик | 12.50 | - |
| 72 | 560140.88 | 1377295.30 | Картометрик | 12.50 | - |
| 73 | 560109.09 | 1377413.89 | Картометрик | 12.50 | - |
| 74 | 560131.21 | 1377451.31 | Картометрик | 12.50 | - |
| 75 | 560152.01 | 1377477.23 | Картометрик | 12.50 | - |
| 76 | 560265.41 | 1377526.84 | Картометрик | 12.50 | - |
| 77 | 560330.63 | 1377528.62 | Картометрик | 12.50 | - |
| 78 | 560386.91 | 1377479.45 | Картометрик | 12.50 | - |
| 79 | 560395.38 | 1377485.19 | Картометрик | 12.50 | - |
| 80 | 560383.36 | 1377559.90 | Картометрик | 12.50 | - |
| 81 | 560458.75 | 1377578.34 | Картометрик | 12.50 | - |
| 82 | 560501.64 | 1377542.55 | Картометрик | 12.50 | - |
| 83 | 560584.14 | 1377563.59 | Картометрик | 12.50 | - |
| 84 | 560609.45 | 1377520.22 | Картометрик | 12.50 | - |
| 85 | 560638.57 | 1377522.31 | Картометрик | 12.50 | - |
| 86 | 560667.77 | 1377560.15 | Картометрик | 12.50 | - |
| 87 | 560767.61 | 1377581.62 | Картометрик | 12.50 | - |
| 88 | 560763.07 | 1377647.18 | Картометрик | 12.50 | - |
| 89 | 560953.98 | 1377607.30 | Аналитик | 7.50 | - |
| 90 | 561004.24 | 1377597.30 | Аналитик | 7.50 | - |
| 91 | 561022.98 | 1377593.84 | Картометрик | 12.50 | - |
| 92 | 561076.95 | 1377580.80 | Картометрик | 12.50 | - |
| 93 | 561300.28 | 1377686.66 | Картометрик | 12.50 | - |
| 94 | 561303.33 | 1377727.41 | Картометрик | 12.50 | - |
| 95 | 561405.18 | 1377775.22 | Картометрик | 12.50 | - |
| 96 | 561523.17 | 1377846.42 | Картометрик | 12.50 | - |
| 97 | 561616.49 | 1377852.30 | Аналитик | 3.00 | - |
| 98 | 561754.31 | 1377855.36 | Картометрик | 12.50 | - |
| 99 | 561751.60 | 1377919.26 | Картометрик | 12.50 | - |
| 100 | 561813.85 | 1377965.94 | Картометрик | 12.50 | - |
| 101 | 561938.94 | 1377985.16 | Картометрик | 12.50 | - |
| 102 | 562085.51 | 1378081.48 | Картометрик | 12.50 | - |
| 1 | 562215.86 | 1378203.92 | Картометрик | 12.50 | - |

3. Объект чиге өлешенең (өлешләренең) характерлы нокталары турында мәгълүматлар

| Чикләрнең характерлы нокталары билгесе | Координатлар, метр | | Характерлы ноктаның координатларын билгеләү ысулы | Характерлы нокта урынының уртача квадрат төгәлсезлеге (Mt), метр | Җирлектә нокта билгесенең тасвир-ламасы (булганда) |
|---|---|---|---|---|---|
| | X | Y | | | |
| - | - | - | - | - | - |


3 бүлек

<table>
<tr><td colspan="8">Объектның үзгәртелгән (тәгаенләнгән) чикләренең урнашу урыны турында мәгълүматлар</td></tr>
<tr><td colspan="8">1. Координатлар системасы: Халыкара координатлар системасы – 16</td></tr>
<tr><td colspan="8">2. Объект чикләренең характерлы нокталары турында мәгълүматлар</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Чикләрнең характерлы нокталарын билгеләү</td><td colspan="2">Гамәлдәге координатлар, метр</td><td colspan="2">Үзгәртелгән (тәгаенләнгән) координатлар, метр</td><td rowspan="2">Характерлы ноктаның координатларын билгеләү ысулы</td><td rowspan="2">Характерлы нокта урынының уртача квадрат төгәлсезлеге (Mt), метр</td><td rowspan="2">Җирлектә нокта билгесенең тасвирламасы (булганда)</td></tr>
<tr><td>X</td><td>Y</td><td>X</td><td>Y</td></tr>
<tr><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td colspan="8">3. Объект чиге өлешенең (өлешләренең) характерлы нокталары турында мәгълүматлар</td></tr>
<tr><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
</table>

4 бүлек

## Объект – «Чепья урманы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле чикләре планы

Объект чикләренең күзәтү схемасы




Масштабы 1 : 25 000

Файдаланыла торган шартлы билгеләр һәм тамгалар

– объект чиге


– җирлек чиге

– торак пункт чиге

4 бүлек

# Объект – «Чепья урманы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле чикләре планы

1 нче бит




Масштабы 1 : 5 000


Файдаланыла торган шартлы билгеләр һәм тамгалар

- • 1 – объект чикләренең характерлы ноктасы билгесе
- (кызыл сызык) – объект чиге
- (шәмәхә сызык) – җирлек чиге
- (яшел сызык) – кадастр кварталы чиге
- (соры сызык) – җир кишәрлеге чиге
- **16:12:150801** – кадастр кварталы номеры
- :11 (16:12:000000:46) – җир кишәрлегенең кадастр номеры

4 бүлек

Объект – «Чепья урманы» төбәк әһәмиятендәге
табигать һәйкәле чикләре планы

2 нче бит




Масштабы 1 : 5 000


Файдаланыла торган шартлы билгеләр һәм тамгалар

| | |
|---|---|
| • 29 | – объект чикләренең характерлы ноктасы билгесе |
| | – объект чиге |
| | – җирлек чиге |
| | – кадастр кварталы чиге |
| | – җир кишәрлеге чиге |
| 16:12:150801 | – кадастр кварталы номеры |
| :12 (16:12:000000:46) | – җир кишәрлегенең кадастр номеры |

4 бүлек

Объект – «Чепья урманы» төбәк әһәмиятендәге
табигать һәйкәле чикләре планы

3 нче бит





Масштабы 1 : 5 000

Файдаланыла торган шартлы билгеләр һәм тамгалар

| | |
|---|---|
| • 57 | – объект чикләренең характерлы ноктасы билгесе |
| (кызыл сызык) | – объект чиге |
| (шәмәхә сызык) | – җирлек чиге |
| (яшел сызык) | – кадастр кварталы чиге |
| (соры сызык) | – җир кишәрлеге чиге |
| 16:12:150801 | – кадастр кварталы номеры |
| :10 (16:12:000000:60) | – җир кишәрлегенең кадастр номеры |

4 бүлек
Объект – «Чепья урманы» төбәк әһәмиятендәге
табигать һәйкәле чикләре планы

4 нче бит




Масштабы 1 : 5 000

Файдаланыла торган шартлы билгеләр һәм тамгалар

| | |
|---|---|
| • 60 | – объект чикләренең характерлы ноктасы билгесе |
| (кызыл сызык) | – объект чиге |
| (шәмәхә сызык) | – җирлек чиге |
| (сызык-нокта) | – торак пункт чиге |
| (яшел сызык) | – кадастр кварталы чиге |
| (соры сызык) | – җир кишәрлеге чиге |
| 16:12:150802 | – кадастр кварталы номеры. |